**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 20 гыйнвар № 25

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 21 гыйнвар, 27 нче карары белән расланган Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 21 гыйнвар, 27 нче карары белән расланган Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

14 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Юридик зат әлеге Тәртипнең 13 нче пунктында күрсәтелгән документларны кертмәсә яки гариза бирүче әлеге Тәртипнең 5 нче пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәсә, Министрлык хәбәрнамәдә күрсәтелгән вакыт

чыккан көннән бер көн эчендә субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.»;

түбәндәге эчтәлекле 20[1] нче пункт өстәргә:

«20[1]. Субсидия бирү турындагы килешүләрдә күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидия хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш.

Субсидия алучы субсидияне кайтару вакытын бозган очракта, Министрлык субсидияне кайтару вакыты чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 7 көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына мәҗбүри рәвештә түләттерү буенча законнар белән билгеләнгән тәртиптә чаралар күрә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\25.docx